Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFƟNYN
## УНИВЕРСИТЕТ

12+

№8 (59)

21 март 2013 ел

## • Универ хәлләре

**15-16 МАРТ КӨННӘРЕНДӘ ЯРЧАЛЛЫ ИНСТИТУТЫНДА** Россиянең алдынгы галим-икътисадчылары – М.В.Ломоносов ис. МДУ профессоры, «Икътисадчы» журналы баш мөхәррире С.С.Губанов, профессор К.А.Хубиев катнашында «Россиядәге икътисади үсешкә заманча якын килү» дигән **ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ УЗДЫ**. Анда шулай ук «КАМАЗ» оешмасыннан да белгечләр катнашты.

• • • •

**18 МАРТ КӨННЕ** ректор **ИЛШАТ ГАФУРОВ** җитәкчелегендә **РЕКТОРАТНЫҢ ЧИРАТТАГЫ УТЫРЫШЫ БУЛДЫ**. Икътисади һәм стратегик үсеш буенча проректор М.Сафиуллин университетның Үсеш программасы белән таныштырды һәм төбәкара инжиниринг үзәген булдыру нияте турында әйтте. Аның фикеренчә, КФУ тәҗрибәсе Кама инновацион территориаль-җитештерү класстерына уңай йогынты ясаячак. И.Гафуров университетта медицина белгечләрен әзерләячәкләре турында хәбәр итте. Кирәкле лицензияне Фундаменталь медицина һәм биология институты алган инде. Алга таба ректор киңәшчесе – иҗтимагый-мәгълүмати үзәк җитәкчесе Ю.Алаев КФУ порталы турында сөйләде. Соңгы айларда эзләтү системаларында аның күренү ресурсы ике тапкырга арткан, порталга керүчеләрнең саны да бермә-бер күбәйгән. Шулай да, порталның эчке һәм тышкы оптимизациясе буенча чишелмәгән мәсьәләләр кала бирә.

• • • •

Шушы көннәрдә Кече Филология һәм сәнгать институтының татар теле, әдәбияты факультетында **АКТАНЫШ** һәм **САБА** гуманитар гимназияләре укучылары өчен **ЧИРАТТАГЫ ДӘРЕС** үткәрелде. Укучыларга онлайн элемтәдә дәресне филология фәннәре докторы Ләйлә Минһаҗева бирде. Талантлы укучылар бу юлы балалар фольклорының үзенчәлекләрен өйрәнделәр. Укучылар шулай ук Филология һәм сәнгать институты директоры Рәдиф Җамалетдинов белән дә аралашты.

• • • •

**18 МАРТТА** ТР Фәннәр академиясендә Казан университетының мактаулы профессоры, танылган астрофизик **РӘШИТ СЮНЯЕВНЫҢ 70 ЯШЬЛЕК ЮБИЛЕЕНА** багышланган тантаналы **ЧАРА** узды. Данлыклы профессорны котларга Казан федераль университеты вәкилләре дә килгән иде. Р.Сюняев актив рәвештә КФУның астрономия һәм космик геодезия кафедрасы белән хезмәттәшлек итә. КФУ ректоры И.Гафуров Рәшит Алиевичка хезмәттәшлеге өчен рәхмәтен белдерде һәм юбилее белән тәбрикләде. «Сез – халкыбызның бренды», – диде.

• • • •

**19 МАРТТА КФУ**ның **IT-ЛИЦЕЕНА** РФ Мәгариф һәм фән министры **ДМИТРИЙ ЛИВАНОВ** килде. Аны ТР Мәгариф һәм Фән министры Э.Фәттахов һәм Казан федераль университеты ректоры И.Гафуров озатып йөрде. Д.Ливанов уку кабинетлары, лабораторияләр, интернат һәм инновацион белем бирү системасы белән танышты. Д.Ливанов табигый-фәнни цикл предметларын укытуны бәяләде, полилингваль укытуның мөһимлеген билгеләп узды. Очрашу барышында IT-лицейга 6 сыйныфны тәмамлаган сәләтле балаларны сайлап алу мәсьәләсе дә каралды.

• • • •

**19 МАРТ КӨННЕ** КФУның Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институтында Фән көне кысаларында студентлар конференциясе узды. Пленар утырышта студентлар һәм аспирантлар журналистика һәм социаль фәннәр өлкәсенә караган аерым мәсьәләләргә багышланган докладлар белән чыгыш ясады.

• • • •

**31 МАРТТА АБИТУРИЕНТЛАР** һәм **СТУДЕНТЛАР** өчен **ИТИС ОЛИМПИАДАСЫНЫҢ ИНТЕРНЕТ-ТУРЫ** узачак. Бу турны уңышлы үткәннәрне икенчы турга университетка чакырачаклар. Анда ИТИС Югары мәктәбендә уку өчен 3 гранта уйнатылачак. Олимпиаданың максаты булып, сыйфатлы IT белем алырга теләгән талантлы абитуриентларны җәлеп итү тора. Тулырак мәгълүматны (843) 233-73-23 телефоны аша алырга мөмкин.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*







Диана Поварова фотолары

# Казан студентлары – сәламәт студентлар!

**Алинә САДЫЙКОВА**, хәбәрче

Шушы көннәрдә университетта бейджик белән йөргән кешеләрнең күплегенә игътибар иткәнсездер. Кемнәр икән, дип баш ватучылар да булгандыр. Алар – 19-21 мартта булган «Караш ноктасы» исемле VI Халыкара студентлар конференциясендә катнашырга теләк белдереп, чит төбәкләрдән, Россиянең башка университетларыннан килгән дусларыбыз.

Конференциянең темасы – «Студентлар арасында һәвәскәр спортны үстерү һәм уку йорты мохитендә сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау: тәҗрибә, проблемалар һәм үсеш перспективасы». Тема юкка гына болай аталмаган. Билгеле булганча, җәй көне Казанда студентлар өчен иң зур масштаблы вакыйга булачак, XXVII Бөтендөнья җәйге универсиадасы үткәреләчәк. Конференциянең максаты да шуннан чыгып билгеләнә: уку йортларында спортны һәм сәламәт яшәү рәвешен үстерүгә үз өлешләрен керткән кешеләрнең үзара тәҗрибә уртаклашуы. Чара кысаларында кунакларны Универсиада спорт объектлары, Универсиада авылы һәм КФУда кабул ителгән спорт эшләре структурасы белән таныштырдылар. Дагстан дәүләт университеты студенты Алихан Магамерзаев: «Казан – Мәскәү һәм Санкт-Петербургтан соң, Россиянең спорт үзәге санала. Монда спортка бүлеп бирелгән бюджет бөтен Дагстанныкына караганда да күбрәктер, мөгаен. Казан бик алга киткән шәһәр һәм мин монда тәҗрибәм белән уртаклашырга килдем. Коллегаларымнан да яңа идеяләр алырга һәм аларны туган ягымда гамәлгә ашырырга телим. Бездә алга киткән спорт төрләре – футбол белән көрәш, ләкин ул гына җитми», – дип, фикерләре белән уртаклашты.

Конференциянең пленар утырышында кунакларны КФУның социаль һәм тәрбия эшләре буенча проректоры Ариф Межведилов, «Буревестник» яшьләр физик тәрбия һәм спорт җәмгыяте рәисе Эмир Харисов, ТР Студентлар Лигасы президенты Тимур Сөләйманов, КФУның Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институты физик тәрбия теориясе кафедрасы профессоры Ринат Абзалов, А.К.Аммосов ис. Төньяк-Көнчыгыш федераль университетының «VITA» Студентларны тернәкләндерү үзәге рәисе урынбасары Павел Ожегов һ.б. сәламләделәр. Татарстанда спортка игътибар арту турында ТР Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгының гаммәви-мәдәни эшләр бүлеге җитәкчесе Станислав Андреев сөйләде: «Республикабызда өч йөз меңгә якын студент һәм аспирант исәпләнә. Бу бик зур интеллектуаль һәм иҗтимагый потенциал. Соңгы 4 ел эчендә спорт белән шөгыльләнүче студентларның саны 62 %ка арткан».

Пленар утырыштан соң, катнашучылар «тәҗрибә алышу»ны секцияләрдә дәвам иттеләр.

## • Бездә кунак бар

# КФУ урманнар сагында

**Ләйсән ИСХАКОВА**, Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

19 мартта КФУның I физика аудиториясендә ТР Урман хуҗалыгы министры Наил Мәһдиев укытучы, студент һәм аспирантлар белән очрашты. Чара Халыкара урман көненә багышланды. Катнашучыларга «Татарстан урманнары: янарыш стратегиясе» дип исемләнгән фильм тәкъдир итепде.

Ахыры 2нче биттә.



Алия Галимуллина фотосы

Юбиляр

# Тату урманның агачы да үз ишеннән

(Татар халык мәкале)

Роза АСЫЛГӘРӘЕВА,
кафедра доценты

**Профессор Чулпан Мөхәррәм кызы Харисова. Гап-гади авыл кызы Чулпан Мортазина. Бу ара ничек үтелгән, нинди хыяллар, тәэсирләр, теләкомтылышлар аңа канат биргән дә, аны бүген ирешкән биеклекләргә күтәргән?**



Чулпан Кукмара районында гына түгел, бөтен Республика, хәтта Россия күләмендә данлыклы Зур Сәрдек мәктәбендә укый. Мәктәп биргән төпле белем, җәмәгать эшләрендә актив катнашуны таләп иткән мохит аның алдагы тормышында да юл күрсәткеч нур булып тора.

Чулпанның күп белергә хирыслыгын, эзләнүчәнлек, иҗади тынгысызлыгын формалаштыруда аның ике малай арасында кыз булуы да зур роль уйный. Абыйэнеләре эшләгән эшләрдә катнашып, әнисенең тавык чүпләп бетермәслек хатынкыз мәшәкатьләрен җиңүдә зур ярдәмче дә булып үсә ул. Гаиләдәге татулык, берберсенә итагатьлелек, олыны олы дип, кечене кече дип күрә белү аңа гомерлеккә сеңдерелгән сыйфатлар булып калды. Бүген мин Чулпанда әнисе Хәтимә апага хас тыйнаклык, пөхтәлек, төгәллек, башлаган эшен тәртипле итеп ахыргача җиткерү сыйфатларын ачык күрәм.

*Менә шулай, бабай каныннан яралган кияү һәм каениш туфрагыннан алынган килен бүген үзләре тату, матур, кешелекле һәм эшлекле гаилә башлыклары. Фән юлыннан киткән уллары Илшат, шулай ук фәннәр кандидаты дәрәҗәләре алган кызлары Гөлшат һәм кияүләре Илназның кадерле әти-әниләре, төпле киңәшчеләре, Харисовлар нәселенең арка таянычлары.*

Безнең кафедра озак еллар буе студентларны, педагогик практика үтү өчен, Зур Сәрдек мәктәбенә алып бара иде. Ә без, укытучылар, традиция буенча, Хәтимә апага урнаша идек. Хәтимә апаның ире Мөхәррәм абыйны олы ихтирам белән искә алуы, әтиләренең балаларда кешелек сыйфатларын тәрбияләүгә керткән өлешен даими ассызыклавы бу гаиләнең чын мәгънәсендә тәрбия учагы булуын раслап тора иде.

Чулпан КДПИның татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга 1970 елда килде. Озын куе чәчле, җитди, тыйнак, әдәпле, һәр дәресенә әзерләнеп йөри торган бу кызны укытучылар бик тиз күреп алды. Аны бигрәк тә академҗитәкчесе Мәдинә Шәйхиевна Җәләлиева яратты, бөтен уку елларында Чулпан Мәдинә апаның уң кулы булды, фәнни эзләнүләргә беренче адымын ясатучысы да ул иде.

Мәдинә апасының фатирына аның соңгы көннәренә кадәр Чулпанның сукмагы суынмады, булдыра алганча ярдәм итеп яшәде, Мәдинә апаны соңгы юлга озатучылар арасында да ул иде. Яраткан укытучысы Зөһрә апа Вәлиуллина лаеклы ялга киткәннән соң, ул укыткан морфология фәнен укытуны дәвам итте һәм шулай ук Зөһрә апаның да соңгы көненә кадәр аның белән аралашып, ярдәм итеп яшәде.

Бу гамәлләрне ул өстенә төшкән бурычны үтәү итеп түгел, гадәти, шулай эшләнергә тиешле эш итеп башкарды. Кафедрабызның бакыйлыкка күчкән шәхесләре Клара Зыя кызы, Мәдинә Шәйхи кызы, Фатыйма Сәгыйрь кызы, Зөһрә Мәҗит кызы каберләренә ел саен бер генә булса да барып, алар рухына дога ирештереп кайтуда да Чулпан - оештырып йөрүчеләрнең берсе.

Укуны кызыл дипломга тәмамлаган Чулпанны фән дөньясына кертеп җибәрәсе килгән иде Мәдинә апаның, тик ничек инде гадәттән тыш җаваплылык тоеп яшәргә өйрәтелгән кыз үзенең төп бурычын – укытучы булып эшләргә тиешлелек бурычын үтәмәсен? Чулпан яраткан мәктәбендә, хөрмәт иткән укытучылары арасында 4 ел буе рус теле һәм әдәбияты укытучысы, уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары булып эшли, әнисен тәрбияли.

Шуннан соң гына, ниһаять, үзенең тагын ике хыялын тормышка ашырырга керешә: яраткан кешесе Фираз Харисовка кияүгә чыгып, әйбәт гаилә төзиләр, оясында алган тәрбия нигезендә, «Ирне ир иткән дә хатын, җир иткән дә хатын» мәкален истә тотып, башта Фираз Фахразовичка фән дөньясына кереп китү мөмкинлеген биреп, балалар үстерү мәшәкатьләренең күп өлешен үз өстенә алды һәм, акрынлап, икенче хыялын да тормышка ашырды: укытучылык эшенә кереп китте, фән дөньясына чумды һәм, озакка сузмыйча, фәннәр кандидаты, фәннәр докторы булуга ирешә. Бүгенге көндә Чулпан Мөхәррәм кызы Харисова – республика күләмендә дә, хәтта Россия күләмендә дә танылган шәхес – күп санлы дәреслекләр, программалар, кулланмалар, сүзлекләр авторы, Татарстанның атказанган укытучысы, атказанган фән эшлеклесе, К.Насыйри ис. премия лауреаты һәм башка бик күп бүләкләр иясе.

Мондый уңышларга ирешүнең чишмә башы – гаилә. Гаиләдә бер-береңне аңлап яшәү, бер-береңә терәк була белү, үзара яхшы мөнәсәбәт – Харисовлар гаиләсе дигән зур гаиләнең тоткасы. «Килен каениш туфрагыннан алына», «Кияү бабай каныннан ярала» ди халык мәкальләре. Чулпан килен булып төшкән нигездәге җылылык, бер-берсенә хөрмәт, кешелеклелек, пөхтәлек, җыйнаклык атмосферасын, Фиразның ата-анасы Фахраз абый белән Газимә апа арасындагы бер караштан бер-берсен аңлауны без үзебез күреп кайткан кешеләр. Чулпанның төшкән урыны да, үз оясындагы кебек, төпле, нык тәрбияле, кеше хакын хак итә белә торган гаилә булып чыкты. Ә дүрт егетнең әти-әнинең бармак селкетүеннән үк нәрсә әйтергә теләгәнен аңлап, шунда ук әле әйтеләсе эшне башкарып та куюлары бу нәселнең асыл сыйфатларына тагын бер ука җеп өсти. Хезмәттәшебез Чулпан Харисованы ихлас күңелдән зур юбилее белән котлап, аңа саулык-сәламәтлек, мул иҗади уңышлар телибез. Ире, шулай ук профессор, педагогика фәннәре докторы Фираз Харисов белән берлектә татар җәмәгатьчелеген, республика һәм Россиянең төрле төбәкләрендә иҗат итүче татар теле һәм әдәбияты укытучыларын иҗат җимешләре белән һәрдаим куандырып торсыннар, дигән теләктә калабыз.

Бездә кунак бар

# КФУ урманнар сагында

**Башы 1нче биттә.**

Билгеле булганча, 2013 ел – экологик культура һәм әйләнә-тирәне саклау елы. Кайчандыр республикабыз күп санлы урманнары белән дан тоткан. Бүген исә Татарстанда урман җир мәйданыбызның нибары 17,5 % ын тәшкилитә. Күршеләребезнең бу күрсәткече бермә-бер артык: Киров өлкәсендә – 63,6 %, Марий Эл республикасында – 56,1 %, Түбән Новгород өлкәсендә 48 %.

Хәзерге көндә урманнарны саклап калу мөһим мәсьәләләр рәтендә каралырга тиеш. Урманнарны рациональ файдалану һәм яңарту – экологик куркынычсызлыкның нигезе. Агачларга сакчыл караш киләсе буын өчен урманны саклап калырга мөмкинлек бирәчәк. Моны һәрберебез ачык аңларга тиеш. Кеше бер елда кулланган урман ресурсларын яңадан торгызу өчен ел ярым-ике ел вакыт кирәк. 1 % урманны аякка бастыру өчен исә ун ел буе, аз дигәндә, 6 гектар мәйданда үсенте утырту зарур.

Янгын куркынычсызлыгын үтәү – урманнарны саклап калуның тагын бер мөһим ысулы. Соңгы елларда республикабызның төрле районнарында махсус янгыннан саклау пунктлары барлыкка килде. Мондый кайгыртучанлыкның нәтиҗәсе дә күзгә күренерлек. Соңгы ике ел эчендә янгын чыгу куркынычы зур булган җәйге чорда бер янгын да булмаган. (Чагыштыру өчен: 2010 елда 100 ләп янгын очрагы күзәтелгән.)



**Наил Мәһдиев** (*фотода*) урманны торгызу мәсьәләсенә дә кагылып узды: Саба районында селекция-орлык үстерү Урман үзәге булдырылган. Әлеге үзәк Россиядә генә түгел, Европада да иң зурлардан санала. Чарада Наил Мәһдиев: «Табигатькә мөнәсәбәт кешенең рухи халәте булырга тиеш», – дигән фикер җиткерде.

Лекция ахырында, укытучылар биргән сорауларга җавап биргәндә, министр КФУ һәм ТР Урман хуҗалыгы арасында хезмәттәшлек турындагы килешүгә кул куелырга әзерлек баруы хакында белдерде. Чынлыкта урманны саклауга багышланган хезмәттәшлек башланган инде. Бу көнне университетыбыз студентлары һәм укытучыларына нарат яки чыршы үстереп карау мөмкинлеге бирелде. Теләүчеләргә, агач утырту өчен, материаллар әзерләнгән иде. Ылыслы үсентеләрне тәрбияләү серләренә министр үзе төшендерде.



*Алия Галимуллина фотолары*

Мөнбәр

# Җиңү белән кайтты

Сөләйман НӘҖМИЕВ




**Филология һәм сәнгать институты татар филологиясе бүлегенең 5 нче курс студенты Илмира Мифтахова Башкортстанда үткән «Ана теле-2013» конкурсында үзенең иҗади һәм һөнәри талантын күрсәтеп, җиңүгә ирешә.**

Мифтахетдин Акмулла ис. Башкорт дәүләт педагогика университетында быел бишенче тапкыр оештырылган конкурста Россия төбәкләрендәге педагогик югары уку йортларында белем алучы яшьләр катнашты. Конкурсның максаты – укытучы һөнәренә мәхәббәт тәрбияләү, мөгаллимлек эшендә яңа алымнар кулланып, туган тел дәресләренең дәрәҗәсен һәм нәтиҗәлелеген күтәрү, талантлы студентларны барлау һәм булачак татар теле һәм әдәбияты укытучыларының хезмәтен бәяләү.

Илмира Мифтахова әлеге конкурста үз портфолиосын, дәрес эшкәртмәсен һәм үзе белем алган институтны тәкъдир итте. «Татар теле дәресе авыр һәм ялыктыргыч булырга тиеш түгел. Шуңа да һәр тема буенча кызыклы уеннар, мавыктыргыч алымнар һәм заманча технологияләрне кулланып эш итү дәреснең нәтиҗәлелеген күтәрә дә инде. Мин белем алган Филология һәм сәнгать институтында мөгаллимнәр әзерләү өчен бар мөмкинлекләр дә тудырылган. Киләчәктә мин, һичшиксез, уку йортында алган белемнәрне гамәлдә кулланачакмын», – дип белдерде. Конкурсның иҗади этабында Илмира «Туган авылым минем» җырын башкарды. Ә инде бишенче этапта ул Уфаның 65 нче гимназиясенең 6 нчы сыйныфында «сан» темасына дәрес бирде. Казан студентының конкурска тәкъдим ителгән иҗади тупланмасы жюри тарафыннан югары бәяләнеп, аңа 1 дәрәҗә диплом һәм кубок тапшырылды.

Кечкенә галимнәр

# «Мин эшләмәсәм, кем эшләр?»

Алинә САДЫЙКОВА, хәбәрче

«Татар кешесенең бәхетле булу юлы – үткәненне ихтирам итеп, үз буыны алдында лаеклы һәм җаваплы гамәл башкара алу бит», – дигән сүзләрне татар филологиясе бүлеге студентлары еш ишетә. Гөлфия Расил кызы Гайнуллина үзенең тормыш тәҗрибәсе мисалында шул җаваплы гамәлнең асылын ача. Гөлфия ханымның фән юлына кереп китүенең чишмә башы кайда? Хәзер аның шул турыдагы фикерләре белән танышабыз.



«Тумышым белән Әгерҗе районында урнашкан, заманында милләтебезгә хезмәт иткән атаклы гыйлем йорты – мәдрәсә гөрләгән Иж-Бубый авылыннан мин. Мәктәптә укыганда, музей-мәдрәсә ачу тантанасына олуг әдип, мәдрәсә тарихын өйрәнгән галим Мөхәммәт абый Мәһдиев килде. Татар зыялылары белән танышуым шул вакытта башланды.

...Дәрестә укытучыбыз үзегездәге иң төп ун сыйфатыны язып куегыз, диде. Минекен укыды да: «Үсмер кыз бит әле үзең, татар икәнлегең белән горурлануың бик куанычлы», – диде. Ул вакытта патриотик тәрбиягә игътибар зур иде. Класс җитәкчебез рус теле укытучысы Җиһангәраева Әлфия Салиховна (рәсемдә) – бик ватанпәрвәр кеше, «Роман-газета»ларга кадәр укыта иде. А.Солженицын һ.б. авторларның лагерь прозасы, рус авыл прозасы белән мин мәктәп чорында ук журналлардан укып таныштым. Татар теле укытучым исә миндә гел әдәбият белгече күрә иде, ул чорда мин укымаган татар журналы, китабы калмагандыр. Ләкин мин җаным-тәнем белән рус әдәбиятына гашыйк идем.

11 сыйныфта чираттагы предмет олимпиадаларының район ара ярышында татар теле, әдәбиятыннан югары урын алуым киләчәгемне хәл итте. Укытучым, җиңүче кыздан бер баллга калыштың, диде. Мин исә: «Сезгә гел әйтә киләм бит, мин татар теле белгече түгел, ә Сез ышанмыйсыз», – дим. Республика олимпиадасына барачагымны китәргә бер көн калгач белдем. Җиңүче кыз авырып китү сәбәпле, тиз арада әзерләп, мине җибәрделәр. Шунда язмышым мине тагын бер укытучы белән очраштырды. Район командасын алып барган әдәбият укытучысы миннән, укуны бетергәч, кем булачагымны сорады. Мин киләчәктә үземне рус әдәбияты укытучысы итеп күрүемне әйттем. Поездда юл буе сөйләшеп бардык. Укытучы апа әйткән бер хакыйкатьне бүгенгәчә хәтерлим: «Әдәбият укыту – авыр эш. Мин бу юлны сайлар алдыннан иң элек ирем, гаиләм белән киңәшләштем. Сез миңа көн саен әдәби әсәр укырга, дәрескә хәзерләнергә, газит-журналларны бер юлын калдырмый укып барырга рөхсәт бирерсезме, дидем. Аларның ризалыгы белән генә мин бу һөнәрне бүген дә җиренә җиткереп башкарам», – диде. Бу сүзләрне мин хәзер бик яхшы аңлыйм. Олимпиадага килгән көнне бик дулкынландым. Кич бөтен укучы балаларны күңел ачу кичәсенә алып киттеләр. Мин, иртәгәге олимпиадага әзерләнәсем бар, дип, укытучымнан рөхсәт сорап бармый калдым. Хәтерлим, ул бик гаҗәпләнде. Иж-Бубый мәктәбенә мин өченче урын белән кайттым. Бу – мәктәпнең республика күләмендәге бәйгеләрдә тәүге уңышы иде. Шуннан соңгы вакыйгалар мине, рус филологиясенә килергә тиешле кызны, татар филологиясе, көнчыгыш телләре һәм тарихы факультетына алып килде. Алда аспирантура, гыйлем йортында мөгаллимлек итә башлау – бары тик язмыш сызган юл гына. Хәзер исә язмышыма рәхмәтлемен! Университет – бөек рухлы гыйлем йорты. Мин университетны яшәешемнең бишеге итеп күрәм. Гыйлем йорты риясыз һәм үзен аямыйча хезмәт иткән мәгърур җаннарны үз итә, сыендыра, туплый».

*Өйдә алты бала, мин – олысы. Авыл йортында кыш җитсә, утын эше, яз, җәй, көз – бакчада. Әни миңа: «Син инде олы бит», – дип алты яшьтә әйтте микән, иртәрәкме, белмим. Өйдә әнинең уң кулы, мәктәптә класс җитәкчесенең таянычы. Мин эшләмәсәм, кем эшләр, дигән хакыйкатьне бик иртә үзләштердем.*

Аталр сүзе - акылның үзе

Күпчелек төрки халыклар Нәүрүзне көн белән төн тигезләшкән 21 мартта бәйрәм итәләр. Нәүрүз, исеменнән үк күренгәнчә, яңа елны каршы алу бәйрәме. Ул фарсы теленнән алынган сүз һәм «яңа көн» дигән мәгънәне белдерә. Бу көнне көн белән төн озынлыгы тигезләшә һәм алга таба көн төннән озыная башлый. Хәзерге вакытта күп кенә илләрдә, мәсәлән, Төркия, Иран, Әзербәйҗан, Үзбәкстан, Төрекмәнстан, Кыргызстан. Казахстанда ул ил күләмендә үткәрелә торган бәйрәм булып киткән.

# Нәүрүз җитте!

Гөлфия КАМАЛИЕВА,
филология фәннәре кандидаты

Нәүрүз Иран халкының борынгы диннәре – зороастризм чорында ук билгеле була. Яңа көн – Нәүрүз иң көчле иҗатчы, ягъни бар кылучы Алла (творец) Ахура-Мазданың явыз Ангро-Майньюны чираттагы җиңүе символы, ул җиңү җәй җитүне белдергән. Бу бәйрәм үлгәннәрнең рухын – фравашины искә алу көне буларак та бәйрәм ителгән.

Ел буена бәла-казалар килмәсен, сөенечтә-шатлыкта яшәргә насыйп булсын өчен, Нәүрүз көнне, йокыдан уянгач беренче эш итеп, бал яки шикәр капканнар. Кешеләр бер-берсенә татлы ризык, мәсәлән, фарсыларда хәлвә бүләк иткәннәр. Төрле җирләрдә: биеклекләрдә, тауларда учак якканнар. Ут ярдәмендә табигатьне «авырулардан, бозыктан, күгәректән, черектән, бозымнардан һ.б.» арындырганнар. Нәүрүз алдыннан йорт-җирне чистартканнар, юганнар, яңа матур киемнәр әзерләгәннәр, һәрбер өйдә тәмле-татлы ашамлыклар пешергәннәр. Бу көнне яшәгән йортларына шул йортлардан чыккан мәрхүмнәрнең рухы кайта, ул рухлар да тәмле исләр белән туклана, дигән ышану да булган.

Нәүрүз җиткәндә, бәйрәм өстәле әзерләп, Кояш Кучкар (Овен) йолдызлыгы аша үткәндә, гаиләнең һәр әгъзасы өстәл артына утырган. Нәүрүз көнне өйгә беренче булып кем керү дә мөһим булган, аңа карап, елның ничек буласын юраганнар. Хатын-кыз керсә, начар, ир кеше керсә – ел бәхетле булачак дип юраганнар. Һәр керүче: «Тагын йөз ел яшәгез!» – дигән сүзләр белән атлап кергән.



Бу ритуал–йолалар Нәүрүз бәйрәменең ватаны булган Иранда шулай уза.

Ә татар халкында бәйрәмнең XIX йөз ахыры, XX йөз башында ничек уздырылуы хакында гына күпмедер мәгълүмат сакланган. Әмма алар күп түгел. Нәүрүз хакында язмача теркәлгән беренче мәгълүматлар Ш.Мәрҗани һәм Каюм Насыйри хезмәтләрендә урын алган.

Нәүрүз көннәрендә яшьләр, балалар, мәдрәсә шәкертләре өйдән-өйгә кереп шигъри теләкләр – нәүрүзләр әйтеп, хуҗаларны бәйрәм белән котлап йөргәннәр. Бу ритуалның фарсы халкыннан ук килгән элементлары да бар. Беренчедән, Нәүрүз күп җирләрдә шәкертләр бәйрәме төсен алган, өйгә изге теләкләр теләп, алар – шәкертләр – үсмер егетләр кергән.

Өй хуҗалары Нәүрүзчеләр өчен алдан ук йомырка буяп, кызыл билле перәннек пешереп, конфет-шикәр әзерләп куйганнар. Нәүрүзчеләрне беркайчан да буш кул белән чыгармаганнар. Нәүрүз текстлары еш кына махсус көй белән дә башкарылган.

*Торыгыз, тор, хуҗалар!*
*Нәүрүз җитте, беләмсез?*
*Нәүрүзчеләр килде сезгә,*
*Ни сөенче бирәмсез?*

Хуҗалар нәүрүзчеләргә күчтәнәч биргәндә, үзләренә артып кире кайтасына ышанганнар. Нинди генә халыкның йола-бәйрәмнәрен карасак та, кунак сыйлау, ризык өләшү, кунакка йөрешү, табын кору – аларның уртак атрибуты булган.

Татар халкы Яңа елны XVIII гасырдан 1 гыйнварда бәйрәм итә башлый. Әмма Нәүрүз әйтү үзенең магик көчен югалтса да, Нәүрүз әйтүләр традиция буенча XX гасыр башларына кадәр дәвам итә.

Нәүрүз текстлары да үзләренең магик көчен югалтып, яшьләрнең, шәкертләрнең күңел ачуларына кайтып кала. Шаян Нәүрүз текстлары – шәкертләрнең үз иҗат җимешләре барлыкка килә.

*– Нәүрүз, Нәүрүз!*
*Кая киттең?*
*– Киттем урам буйлап,*
*Хуҗалардан аш-су юллап.*

Нәүрүз теләкләрендә тагын бер тема аерылып тора. Ул җиткән кызлары булган йортларда башкарыла торган текстлар:

*Ачуланма безләргә,*
*Әйтик чыгып сезләргә;*
*Без килдек кыз күзләргә,*
*Котлы булсын яз.*

Яшьләр өчен Нәүрүз танышырга, бер-берсен очратырга уңайлы вакыт була.

Фән дөньясында



# Бөек ефәк юлында

Илмир ВӘЛИЕВ,
Математика һәм механика институты

Соңгы ун ел эчендә Россия-Төрекмән дәүләтара бәйләнеш кысаларында Татарстан белән Төрекмәнстан тагын да якынайды. 14-16 мартта Ашхабад шәһәрендә узган «Бөек ефәк юлы дипломатиясе: тарихтан киләчәккә таба» исемле фәнни конференция шуның ачык мисалы булып тора.

Чара Төрекмәнстан тышкы эшләр министрлыгының Халыкара мөнәсәбәтләр институтына биш яшь тулу уңаеннан, Төрекмәнстан Президенты Гурбангулы Бердымухамедов инициативасы белән оештырылган. Конференциядә катнашырга Төрекмәнстан һәм Россия Федерациясе, АКШ, Бөекбритания, Кытай, Япония, Төркия һ.б. илләрнең югары уку йортлары, фәнни үзәк галимнәре һәм әйдәп баручы белгечләр теләк белдергән. Төрекмәнстанның РФдагы вәкиле Б.Рәджәпов һәм оештыручылар чакыруы буенча, конференциядә Мәскәү дәүләт халыкара мөнәсәбәтләр институты профессоры Д.Васильев һәм Казан федераль университеты Тарих институты профессоры А.Борһановлар чыгыш ясады. «Бөек ефәк юлы системасында Татарстан-Төрекмәнстан (Россия-Төрекмән дәүләтара бәйләнеш кысаларында Татарстан-Төрекмәнстан мөнәсәбәте. Үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге)» докладында Альберт Борһанов (*фотода унда*) татарларның төрекмән һәм башка Көнчыгыш халыклары белән булган бәйләнеше, аның еракка киткән тамырлары, Татарстанның Төрекмәнстан белән хезмәттәшлеге, алдагы перспективалар турында сөйләде.

Шушы көннәрдә Ашхабад шәһәрендә Нәүрүз бәйрәме кысаларында «Нәүрүз – тынычлык һәм яхшылык бәйрәме» Халыкара фәнни конференция уза. Анда да уку йортыбыздан галимнәр катнаша.

● Җырлыйбыз да, биибез дә!

# Биючегә сүз әйтмәгез...

**Динара МИННЕКАЕВА**,
хәбәрче

Казаныбызга «җырчы-башкала» исемен безнен студентыбыз Динә Гарипова алып кайтты. Сүз уңаеннан, ул Россия данын май аенда Швециядә Мальма шәһәрендә үтәчәк Евровидение конкурсында яклаячак. Мәркәзебез җырчы гына түгел, биюче дә булып куймагае.



### Иң текә дискәтүк!

9 март көнне «Россия 1» телеканалында яңа бер зур проект старт алды. Анда Мәскәү, Санкт-Петербург, Саратов, Самара, Волгоград, Түбән Новгород һәм Ростов-на-Дону шәһәрләре белән бергә Казан командасы да көч сынашачак. Һәр команда 100әр кешедән тора. Татарстан данын Казан шәһәрендә яшәүчеләрдән тыш, Яр Чаллы, Яшел Үзән, Түбән Кама биючеләре дә яклаячак. Иң мөһиме: талантлар арасында Казан федераль университеты студентлары бар.

Мондый зур чараның әле беркайчан да оештырылганы юк иде. Беренче тапшыруда бөтен командалар да бер сәхнәдә биеде. Менә бу дискәтүк, ичмасам! Күпме көч, энергия, физик әзерлек, сабырлык, ватан алдында зур җаваплылык таләп итә торган дискәтүк! «Казан командасының җиңү өчен мөмкинлекләре бик зур. Ул башкалардан оешкан, бердәм булуы белән аерылып тора. Биючеләре бик талантлы һәм көчле», – дип бәяләде «Большие танцы» проектының төп куючы-хореографы Пол Домейн. Уңышлы чыгыш ясаган очракта, казанлылар һәр атна саен, программада катнашу өчен, Мәскәүгә барып йөриячәк. Ә репетицияләр Казанда узачак. Һәр тапшыруга катнашучылар дүрт төрле бию әзерләргә тиеш булачак.

### Беренче җиңү!

Проектны ачу тантанасында ук Татарстан командасы үзенең көчле булуын күрсәтте. Жирәбә буенча, безнекеләр иң көчле командаларның берсе Самара белән көч сынашты. Конкурсның беренче этабында командалар үз шәһәрен тәкъдир итте. Казан биючеләре спорт калейдоскопы рәвешендә Җәйге Универсиаданы җиде спорт төре ярдәмендә күрсәтте. 20 баллы бәяләүдән безнекеләр 19ны җыеп, Самара командасын узды. Жюри әгъзасы – актриса Рената Литвинова – Татарстан командасы чыгышын югары бәяләп, Казанны һәм аннан килгән команданы яратуын әйтте.

Икенче этапта безнең талантлар Кристина Орбакайте белән чыгыш ясап, бөтен кешене таң калдырды. Жюрида утыручы актер Андрей Житинкин: «Казанлылар Россиядә дөнья күләмендәге мюзикл куеп була икәнлеген исбатлады», – диде һәм команда максималь 20 баллга ия булды.

Алдагы сынау да җиңелләрдән түгел иде. Һәр ике командадан биючеләр чиратлашып чыгып, үзләренең брейкданс, локинг, хип-хоп һ.б. юнәлешләрдә осталыкларын күрсәтте. Ике команда да җиңүгә иреште

Йомгаклау этабында командалар ирекле номер әзерләгән иде. Казанлылар тормыш һәм биюнең үзара ни дәрәҗәдә тыгыз бәйләнештә булуын раслады. Нәтиҗәдә, беренче сынауда Татарстан командасы 9 балл өстенлек белән җиңеп чыкты.



### Кемнәр алар?

Команда составында төрле яшьтәге, төрле урыннарда эшләүче, укучылар бар. Минем ике конкурсантка аерым тукталасым килә. Күпләр аларны ишетеп беләдер, чөнки бу дәрәҗәдә актив, позитив, һәрвакыт күтәренке кәефле кызларны минем әле очратканым юк иде. Бу кызларны һәркем таный, чөнки аларның катнашмаган концертлары, өлгермәгән җирләре юк! Динара һәм Айнура Кәримовалар (*өстәге рәсемдә)* – Филология һәм сәнгать институтының сәнгать бүлеге студентлары. Омск шәһәрендә туганнар. Мәктәпне тәмамлагач, кызлар Омск техник университетына укырга керәләр. Бер ел уку дәвамында, үзләренең бу өлкә кешеләре түгеллекләрен аңыйлар. «Әти-әниләрне Казанга хореографиягә укырга җибәрергә күндерү җиңел булмады. 6 яшьтән бирле биибез. 13 яшькә кадәр эстрада хореографиясе белән шөгыльләндек, аннары рус халык биюләре кызыксындырды. 16 яшьтә, чын татар кызлары икәнлегебезне аңлап, «Умырзая» халык вокал-хореография ансамбленә йөри башладык. Рәхәтләнеп татарча җырлыйбии идек. Ләкин күңел һаман Казанга – бөтен татар халкының башкаласына тартты. Монда тел, әдәбият, мәдәниятебез бик югары дәрәҗәдә. Гомумән, татарлар арасында яшәүнең нәрсә икәнен беләсебез килде», – ди Динара.

Кызлар куйган максатларына ирешә торганнардан. Проектның сайлап алу турына ике дә уйлап тормыйча барганнар һәм команда составына эләккәннәр. Кызлар, биюдән тыш, гитарада уйный, инглиз телен өйрәнеп, тәрҗемәче булырга әзерләнә.

Биючегә сүз әйтмәгез, бии-бии остара, дигән сүзләр белән килешми мөмкин түгел. Татарстан данын яклаучы биючеләр дә ике тапшыру эчендә үзләренең ни дәрәҗәдә профессиналь, оста икәнлекләрен күрсәтте. Алда аларны зур сынау көтә! Уңышлар һәм җиңүләр телибез Сезгә!!!

● Мәсьәләгә ике караш

# Төн... китаплар арасында

**Ләйсән ИСХАКОВА**,
Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Беркөнне дус кызым шалтыратып, бер эшкә барып акча эшләп алырга тәкъдим итте. Китап кибетендә, гадәттә, елга бер генә була торган үзенчәлекле ревизия-тикшерү булачак икән. Кибетләр көн дә ялларсыз эшләгәнгә, тикшерүне төнлә үткәрәләр. Бу турыда әле моңа кадәр ишеткәнем юк иде. Шуңа үземә дә кызык булып китте. Өстәвенә, хезмәтемә акча да түләнәчәк бит.

Казандагы китап кибетләре челтәренең төп базасына баргач, башта биредә эшләүчеләр белән таныштырдылар. Идәннән түшәмгә кадәр сузылган киштәләр. Нинди генә эчтәлекле, формалы китап юк биредә – исең-акылың китәр…



Иң элек Мәскәү һәм Түбән Новгородтан килгән ревизорлар безгә кечкенә кул сканерларын өләште. Сканер, үзенчәлекле тавыш чыгарып, һәр китапка сугылган махсус штрих-код буенча үтә дә, экранга тиешле язу чыгара. Китап искергән булса, аны аерым тартмага саласың. Ә яңалары киштәдә кала. Йөзләгән китап, сканер тавышы… һәм йокы килү. Кичке сигездә башланган эш берничә мәртәбә кофе тәнәфесенә бүленде бүленде: башкача мөмкин түгел. Ниһаять, иртәнге өчтә эшне төгәлләдек. Нәтиҗәдә тартма-тартма искергән китап исемлектән сызылды. Биек кибет киштәләре бушап калгандай булды. Анысы куркыныч түгел – иртәгә үк яңа партия китаплар кайтырга тиеш. Димәк, укырга яратучылар кытлык кичермәячәк.

Мондый үзенчәлекле тикшерү нәтиҗәсендә күпме китапның искеяңа булуын гына түгел, күпмесенең урланган булуын исәпләү дә авыр түгел. Бүген әсәр укучылар бармак белән генә санарлык, дип сөйләнсәк тә, укыйлар икән. Юкса, аның кадәр китапны нинди максат белән урларга кирәк?

Кечкенәрәк кибетләрдә һәр китап югалу олы вакыйга саналса, зур сәүдә йортларында урланган китаплар бәясе меңнәр белән исәпләнә. Кышын юкка чыгулар җәй белән чагыштырганда күбрәк була икән. Калынрак кием – хәрәм малны яшерү өчен яхшы мөмкинлек. Дөрес, китапларга махсус саклау чиплары беркетелә, әмма каракка аны алып ату берни тормый. Шуңа кибеттәге турникет аша узганда бурларны эләктерү мөмкин түгел.

Нинди китапларны күбрәк урлыйлар икән? Китап кибетендә эшләү дәверендә күпне күргән Диләрә сүзләренә караганда, кемнедер китапның тышкы кыяфәте кызыктыра, ә кайберәүләр максатчан рәвештә үзенә кирәкле материал яки яраткан автор басмасын «эләктерергә» тырыша. Бервакыт хәтта билгеле бер язучының тулы бер киштәсе юкка чыккан. Ис китәрлек бит бу! Хатын-кызлар махсус саклау чиплары булмаган балалар китапларына күз салса, студентлар аерым фән буенча уку әсбаплары белән «кызыксына». Тотылган карак штраф түләү белән котылачак…

Психологлар фикеренчә, китап укучы ТВ караучыдан саурак була икән. Чөнки экраннардан һәрдаим агылган тискәре мәгълүмат нерв системасына начар тәэсир итә. Ә китап укучы моның белән очрашмый гына түгел, ә, киресенчә, укып, тормыш куйган авыр сорауларга җавап та таба. Уку – үзенчәлекле психотерапия мөмкинлеге дә. Аның библиотерапия дип аталган юнәлеше кешене тискәре рухи халәттән арындырырга сәләтле. Моның өчен махсус сайлап алынган матур әдәбият әсәрләрен укырга гына кирәк. Ләкин бу һич кенә дә китапларны урларга ярый дигәнне аңлатмый!

● Студентлар рекорды

# Иң зур «шерри-трифл»

Студентлар һәрвакыт кешелекнең прогрессив өлеше булып торды. Борын-борыннан төрле сәерлекләр кылыр өчен, аларның көчләре дә, фантазияләре дә җиткән. Гиннес рекордлар китабына теркәлгән очраклар моның шулай икәнлеген тагын бер кат дәлилли.

Тбилиси техник университеты студенты Георгий Чхаидзе Гиннес рекордлар китабына 9 урынлы саннарны хәтердән тапкырлап кереп калган. Рекорд өчен претендентка 948 645 332ны 823 452 701гә тапкырларга кирәк була. 781 164 560 926 441 732 дигән дөрес җавапны Георгий 1 сәг. 25 минуттан соң бирә.

Smart автомобиленә сыю буенча рекорд та студентлар тарафыннан куела. 13 кыз автомобильгә кереп урнашу гына түгел, 5 метр аралык юлны, конкурс таләпләре буенча, ябык ишекләр белән үтә дә алган. 13,5 секунд вакыттан соң, катнашучы кызларның сабырлыгы бетеп, эксперимент тәмамлана. Шулай да алар яңа рекорд куюга ирешә. Кызлар машинада элеккеге күрсәткечтән 2,3 секундка озаграк тора.

Җир шарындагы иң зур «шерри-трифл» (пирожное) 1990 елның 26 сентябрендә Бөекбританиянең Клерендол колледжы студентлары тарафыннан пешерелә. 3,13 т. авырлыгындагы әлеге тәмлүшкәне әзерләү өчен 90 л шерри тотылган.

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова, З.Ф.Фәсхиева
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.